Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

18 ноябрь 2020 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 18 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

1. Су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;

2. Балалар уен мәйданчыгы сатып алу;

3. Кече Камышлы торак пункты чикләрендә эчке торак юлларын ремонтлау» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 124 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 77 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 67 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 10 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
1. Су белән тәэмин итү чыганакларына карата норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр башкару;
2. Балалар уен мәйданчыгы сатып алу;
3. Кече Камышлы торак пункты чикләрендә эчке торак юлларын ремонтлау» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Кече Камышлы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.В. Яманов

Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы: А.В. Яманов